| СОВЕТ СМАИЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СМӘЕЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 июнь 2021 ел. № 25

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге Советының 12.03.2021 елда кабул ителгән «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 20 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге Советының 12.03.2021 елда кабул ителгән «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 20 нче номерлы карарына (21.04.2021ел №23 үзгәрешләр белән) (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

   1.1.Карарнын атамасын “физик һәм юридик затлар милкендә булган җирләр” сүзләренә өстәргә”;

2.1. Карар белән расланган, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә керми торган яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәгәдә:

   1) нигезләмәнең исемен “физик һәм юридик затлар милкендә булган җирләр” сүзләренә өстәргә”;

2) пунктлар 2.2.2, 2.4, 3.3.1 – 3.3.7, 3.5, 3.14, 3.16, 3.17 һәм 3.18 төшереп калдырырга;

3) 2.3 пунктта «милекчеләр» сүзен төшереп калдырырга;

4) 3.2 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә::

«Агач һәм куаклар кисүгә, кронлауга һәм утыртуга рөхсәт гариза бирү көнен дә кертеп, 13 көн эчендә бирелә.»;
5) 3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3.3. Рөхсәт бирү гариза бирүченең салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычы булмаганда, Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиеш (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш).»;
6) 3.11 пунктында «рөхсәт ителергә мөмкин» сүзләрен «рөхсәт ителә»сүзенә алмаштырырга.
7) 3.13 пунктта « № 2 кушымта нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;
8) 1 һәм № 2 кушымталарны төшереп калдырырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru),Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә (бастырып чыгарырга).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Смәел авыл җирлеге башлыгы                Р.Г.Йосыпов